**Соглашение**
**между Правительством Республики Татарстан и Правительством Челябинской области о сотрудничестве в экономической, культурной, социальной и иных сферах**

Правительство Республики Татарстан в лице Президента Республики Татарстан Минниханова Рустама Нургалиевича, действующего на основании Конституции Республики Татарстан, с одной стороны, и Правительство Челябинской области в лице Губернатора Челябинской области Текслера Алексея Леонидовича, действующего на основании Устава (Основного Закона) Челябинской области, с другой стороны, именуемые в дальнейшем Стороны,

руководствуясь Конституцией Российской Федерации, законодательством Российской Федерации, законами и иными правовыми актами Республики Татарстан и Челябинской области (далее – законодательство),

в целях развития межрегиональных связей на основе принципов равноправия и взаимной выгоды, укрепления правовой основы сотрудничества с учетом политических и экономических изменений в Российской Федерации,

признавая, что расширение взаимовыгодного сотрудничества отвечает интересам населения Республики Татарстан и Челябинской области и способствует экономическому развитию Республики Татарстан и Челябинской области,

выражая взаимную заинтересованность в развитии двусторонних связей на стабильной и долгосрочной основе и желая создать для этого соответствующие организационные, экономические, правовые и иные необходимые условия, согласились о нижеследующем:

Статья 1

Стороны развивают сотрудничество на основе взаимного уважения, равенства, партнерства и экономической выгоды.

Стороны в пределах своих полномочий создают благоприятные условия для разностороннего развития отношений.

В соответствии с законодательством и в пределах предоставленных полномочий Стороны создают условия для установления и расширения торгово-экономических связей между хозяйствующими субъектами, осуществляющими свою деятельность на территориях Республики Татарстан и Челябинской области (далее – хозяйствующие субъекты).

Статья 2

Стороны воздерживаются от действий, которые могли бы нанести экономический или иной ущерб друг другу, согласовывают и обмениваются информацией о намечаемых решениях, принятие которых может затронуть права и законные интересы Сторон.

Статья 3

В сфере торгово-экономического, инвестиционного и инновационного сотрудничества Стороны в соответствии с законодательством в пределах своих полномочий:

способствуют развитию торгово-экономических связей между хозяйствующими субъектами;

способствуют осуществлению поставок необходимых видов продукции производственно-технического назначения, товаров народного потребления и продовольствия;

содействуют созданию условий для установления и расширения деловых контактов между хозяйствующими субъектами, разработке и реализации программ по развитию и поддержке предпринимательства в Республике Татарстан и Челябинской области;

взаимодействуют при выработке совместных решений по осуществлению инвестиционной и инновационной деятельности, в том числе организуют бизнес-миссии и презентации инвестиционных площадок и инвестиционного потенциала, обмениваются опытом по реализации инвестиционных проектов в рамках официальных визитов и рабочих встреч, информируют о проведении на территории Республики Татарстан и Челябинской области инвестиционных форумов, конференций и иных мероприятий инвестиционной направленности;

развивают механизмы государственно-частного партнерства в рамках положений законодательства Российской Федерации о государственно-частном партнерстве;

обмениваются информацией о нормативных правовых актах Республики Татарстан и Челябинской области и их проектах в сфере развития инвестиционной деятельности;

взаимодействуют по вопросам формирования эффективной системы коммуникации в области науки, технологий и инноваций, а также выстраивания взаимодействия сектора исследований и разработок с реальным сектором экономики, в том числе посредством интернет-портала «Российский центр открытых инноваций «Инноскоп».

Статья 4

В сфере сельского хозяйства, государственного ветеринарного надзора и устойчивого существования животного мира Стороны в соответствии с законодательством в пределах своих полномочий осуществляют обмен опытом по следующим направлениям:

растениеводство, селекция, семеноводство, взаимное использование передовых технологий, растительного генофонда, экологически чистых методов и средств защиты растений при возделывании зерновых и прочих сельскохозяйственных культур;

животноводство, разведение, содержание и кормление высокопродуктивных сельскохозяйственных животных на базе современных

технологий, оказание содействия осуществлению технического обновления механизированных ферм;

биотехнология, биотехнологическое управление производством сельскохозяйственных культур и размножением животных;

перерабатывающая, пищевая промышленность, комплексное использование средств механизации и автоматизации производственного процесса.

Статья 5

Стороны способствуют обмену научно-практической информацией о достижениях в области здравоохранения, обмену делегациями в целях изучения передового опыта в области охраны здоровья населения и повышения качества предоставляемой медицинской помощи на территориях Республики Татарстан и Челябинской области.

Статья 6

В сфере социальной защиты и занятости населения Стороны в соответствии с законодательством в пределах своих полномочий:

осуществляют обмен опытом в части обеспечения занятости населения, социальной поддержки и социального обслуживания населения, в том числе по вопросам принятия и реализации нормативных правовых актов в указанных областях, осуществляют взаимодействие и обмен опытом работы по реализации программ социально-экономического развития, социальных программ поддержки семьи, материнства, детства, граждан пожилого возраста и инвалидов;

обмениваются делегациями специалистов органов социальной защиты и службы занятости населения и учреждений социального обслуживания населения для изучения опыта работы в части внедрения новых социальных технологий;

обмениваются информационно-аналитическими материалами по состоянию безработицы и положению на рынке труда.

Статья 7

В сфере охраны окружающей среды и обеспечения экологической безопасности Стороны в соответствии с законодательством в пределах своих полномочий:

обмениваются информацией о проводимых в Республике Татарстан и Челябинской области мероприятиях по вопросам охраны окружающей среды и обеспечения экологической безопасности;

осуществляют обмен опытом в области организации, охраны и использования особо охраняемых природных территорий, ведения красных книг, охраны и использования объектов животного мира, водных биоресурсов;

способствуют сотрудничеству и обмену опытом по вопросам: обращения с отходами производства и потребления, внедрения новых технологий сортировки, переработки и утилизации отходов, совершенствования управления природоохранными структурами.

Статья 8

В сфере культуры Стороны в соответствии с законодательством в пределах своих полномочий:

осуществляют обмен информацией о предстоящих культурных событиях и мероприятиях, в том числе имеющих международный характер, с целью возможного участия в них коллективов и исполнителей из Республики Татарстан и Челябинской области;

оказывают содействие укреплению и развитию культурных связей;

осуществляют взаимодействие по вопросам организации гастролей творческих коллективов, обменных музейных, художественных и книжных выставок;

осуществляют взаимодействие и обмен опытом по вопросам сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия.

Статья 9

В сфере архивного дела Стороны в соответствии с законодательством в пределах своих полномочий:

осуществляют обмен опытом и информацией о нормативных и методических разработках, информационных технологиях в области архивного дела, применяемых в деятельности архивных органов и учреждений;

принимают участие в организации и проведении научно-практических конференций, семинаров, совещаний, выставок архивных документов, в подготовке публикаций по документам Архивного фонда Российской Федерации;

оказывают содействие друг другу в доступе к архивным документам и научно-справочным материалам, необходимым для исследований и удовлетворения социально-правовых запросов граждан в соответствии с законодательством.

Статья 10

В сфере образования и науки Стороны в соответствии с законодательством в пределах своих полномочий:

проводят совместные конференции;

реализуют совместные научно-исследовательские проекты;

обмениваются опытом по разработке современных образовательных технологий, проектов нормативных правовых актов, регулирующих деятельность образовательных организаций;

осуществляют взаимодействие и обмен опытом по вопросам сохранения и развития этнокультурного образования.

Статья 11

В сфере информатизации и связи Стороны в соответствии с законодательством в пределах своих полномочий:

развивают взаимовыгодное сотрудничество в области информационных технологий, в том числе путем реализации различных инвестиционных проектов;

осуществляют обмен опытом (в том числе техническими решениями) по разработке и внедрению новейшего программного обеспечения;

осуществляют обмен делегациями представителей Сторон с целью изучения передового опыта по вопросам развития отраслей информационных технологий и связи;

стимулируют развитие наукоемких отраслей, в том числе путем создания совместных предприятий.

Статья 12

В сфере спорта Стороны в соответствии с законодательством в пределах своих полномочий осуществляют содействие участию спортсменов и спортивных сборных команд Республики Татарстан и Челябинской области в спортивных мероприятиях.

Стороны осуществляют взаимодействие по линии спорта в рамках Единого календарного плана межрегиональных, всероссийских и международных физкультурных мероприятий и спортивных мероприятий по подготовке к ним по различным видам спорта при проведении соревнований и учебно-тренировочных сборов.

Статья 13

В сфере молодежной политики Стороны в соответствии с законодательством в пределах своих полномочий оказывают содействие участию молодежи в мероприятиях, реализуемых Сторонами.

Статья 14

В сфере туризма Стороны в соответствии с законодательством в пределах своих полномочий:

осуществляют обмен информацией о предстоящих мероприятиях Республики Татарстан и Челябинской области в сфере туризма;

оказывают содействие в установлении взаимных контактов между туристскими организациями Республики Татарстан и Челябинской области.

Статья 15

В сфере строительства, архитектуры, энергетики и жилищно-коммунального хозяйства Стороны в соответствии с законодательством в пределах своих полномочий:

обмениваются опытом в области организации строительства, градостроительной политики, энергетики и жилищно-коммунального хозяйства;

обмениваются делегациями органов государственной власти, осуществляющих полномочия в области строительства, архитектуры, энергетики и жилищно-коммунального хозяйства;

участвуют в международных, республиканских и областных выставках, семинарах и конференциях в сфере строительства, архитектуры, энергетики и жилищно-коммунального хозяйства.

Статья 16

В сфере международных связей Стороны информируют друг друга о мероприятиях международного характера, проводимых в Республике Татарстан и Челябинской области.

Статья 17

В области регулирования цен (тарифов) Стороны в соответствии с законодательством в пределах установленных полномочий осуществляют обмен опытом и информацией в рамках вопросов тарифного регулирования, правоприменительной практики и контрольно-надзорной деятельности.

Статья 18

В сфере реализации государственной национальной политики Стороны в соответствии с законодательством в пределах своих полномочий:

содействуют сближению и взаимообогащению культур народов, проживающих на территориях Республики Татарстан и Челябинской области;

создают необходимые условия для удовлетворения национально-культурных интересов народов, проживающих на территориях Республики Татарстан и Челябинской области;

участвуют в разработке и реализации совместных проектов по взаимодействию с национально-культурными объединениями;

при организации визитов рассматривают предложения о включении в составы делегаций руководителей национально-культурных объединений.

Статья 19

Стороны сотрудничают по вопросам взаимного участия представителей средств массовой информации Республики Татарстан и Челябинской области в региональных и межрегиональных профессиональных и обучающих мероприятиях (форумах, фестивалях, конференциях, семинарах).

Стороны осуществляют обмен опытом о формах государственной поддержки региональных и муниципальных средств массовой информации, в том числе поддержки социально значимых проектов, реализуемых средствами массовой информации.

Стороны содействуют организации информационного обмена между средствами массовой информации Республики Татарстан и Челябинской области в части общественно-политической, экономической, научной и культурной жизни Республики Татарстан и Челябинской области.

Статья 20

Настоящее Соглашение не налагает на подписавшие его Стороны финансовых или имущественных обязательств.

Статья 21

В целях реализации настоящего Соглашения Стороны вправе заключать договоры (соглашения), планы мероприятий, осуществлять совместные мероприятия в конкретных областях сотрудничества.

Настоящее Соглашение не затрагивает обязательств Сторон по заключенным договорам (соглашениям) с третьими сторонами и не может быть использовано в ущерб интересам какой-либо из них или служить препятствием для выполнения взятых перед третьими сторонами обязательств.

Положения настоящего Соглашения не могут рассматриваться как создающие благоприятствующие условия для деятельности отдельных хозяйствующих субъектов, которые могут иметь своим результатом ограничение конкуренции или ущемление интересов иных хозяйствующих субъектов.

Статья 22

Стороны оперативно рассматривают возникающие в процессе реализации настоящего Соглашения вопросы и принимают необходимые меры по их положительному разрешению в соответствии с законодательством.

Статья 23

Разногласия, связанные с толкованием и (или) применением положений настоящего Соглашения, разрешаются путем проведения переговоров и консультаций между Сторонами.

Статья 24

Настоящее Соглашение вступает в силу со дня его подписания и действует в течение пяти лет. В дальнейшем Соглашение автоматически продлевается на следующие пятилетние периоды, если ни одна из Сторон не заявит в письменной форме о своем желании прекратить его действие.

Настоящее Соглашение прекращает действие по истечении шести месяцев со дня получения одной из Сторон письменного уведомления от другой Стороны о своем намерении прекратить его действие.

Изменения в настоящее Соглашение вносятся по взаимному согласию Сторон дополнительными соглашениями, являющимися неотъемлемой частью настоящего Соглашения.

Совершено в г. Челябинске «1» октября 2020 года в двух экземплярах, на русском и татарском языках, имеющих одинаковую силу, по одному экземпляру для каждой из Сторон.

| За Правительство Республики Татарстан | За Правительство Челябинской области |
| --- | --- |
| Президент Республики Татарстан | Губернатор Челябинской области |
| Р.Н. Минниханов | А.Л. Текслер |

02.10.2020
№ 22

**Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Чиләбе өлкәсе Хөкүмәте арасында икътисадый, мәдәни, социаль һәм башка өлкәләрдә хезмәттәшлек турында килешү**

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Президенты Миңнеханов Рөстәм Нургали улы йөзендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте, бер яктан, һәм Чиләбе өлкәсе Уставы (Төп Законы) нигезендә эш итүче Чиләбе өлкәсе Губернаторы Текслер Алексей Леонидович йөзендә Чиләбе өлкәсе Хөкүмәте, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталып,

Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсе законнарына һәм башка хокукый актларына (алга таба – законнар) таянып,

тигез хокуклылык һәм үзара файда принциплары нигезләрендә төбәкара бәйләнешларны үстерү, хезмәттәшлекнең хокукый нигезләрен Россия Федерациясендәге сәяси һәм икътисадый үзгәрешләрне исәпкә алып ныгыту максатларында,

үзара файдалы хезмәттәшлекне киңәйтүнең Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсе халкы мәнфәгатьләренә туры килүен һәм Татарстан Республикасының һәм Чиләбе өлкәсенең икътисадый үсешенә булышлык итүен танып,

ике яклы элемтәләрне тотрыклы һәм озак вакытлы нигездә үстерүгә үзара кызыксыну күрсәтеп һәм моның өчен тиешле оештыру, икътисадый, хокукый һәм башка кирәкле шартлар булдырырга теләп, түбәндәгеләр турында килештеләр:

1 статья

Яклар хезмәттәшлекне үзара хөрмәт рухында, тигезлек, партнерлык һәм икътисадый файда нигезендә үстерә.

Яклар үз вәкаләтләре чикләрендә мөнәсәбәтләрне төрле яклап үстерү өчен уңайлы шартлар булдыра.

Законнар нигезендә һәм бирелгән вәкаләтләр чикләрендә Яклар Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсе территорияләрендә эшчәнлек алып баручы хуҗалык субъектлары (алга таба – хуҗалык субъектлары) арасында сәүдә-икътисадый элемтәләр урнаштыру һәм үстерү өчен шартлар булдыра.

2 статья

Яклар бер-берсенә икътисадый яисә башка зыян китерерлек гамәлләрдән тыела, аларны кабул итү Якларның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылырга мөмкин булган ниятләнгән карарларны килештерә һәм алар турында мәгълүмат алмаша.

3 статья

Яклар сәүдә-икътисадый, инвестиция һәм инновация хезмәттәшлеге өлкәсендә законнар нигезендә һәм вәкаләтләре чикләрендә:

хуҗалык субъектлары арасында сәүдә-икътисадый элемтәләрне үстерүгә ярдәм итә;

җитештерү-техник билгеләнештәге продукциянең кирәкле төрләре, халык куллану товарлары һәм азык-төлек белән тәэмин итүне тормышка ашыруга булышлык итә;

хуҗалык субъектлары арасында эшлекле багланышлар булдыру һәм аларны киңәйтү өчен, Татарстан Республикасында һәм Чиләбе өлкәсендә эшкуарлыкны үстерү һәм аңа булышлык күрсәтү программалары эшләү һәм аларны гамәлгә ашыру өчен шартлар булдыруга ярдәм итә;

инвестиция һәм инновация эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча уртак карарлар эшләүдә хезмәттәшлек итә, шулай ук бизнес-миссияләр, инвестиция мәйданчыклары һәм инвестиция мөмкинлекләрен тәкъдим итүне оештыра, рәсми визитлар һәм эшлекле очрашулар кысаларында инвестиция проектларын гамәлгә ашыру тәҗрибәсен алмаша, Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсе территорияләрендә инвестиция форумнары, конференцияләр һәм инновация эшчәнлегенең башка чаралары уздыру турында хәбәр итә;

Россия Федерациясенең дәүләт-хосусый партнерлык турында законнары нигезләмәләре кысаларында дәүләт-хосусый партнерлык механизмнарын үстерә;

Татарстан Республикасының һәм Чиләбе өлкәсенең норматив хокукый актлары һәм аларның инвестиция эшчәнлеген үстерү өлкәсендәге проектлары турында мәгълүмат алмаша;

фән, технологияләр һәм инновацияләр өлкәсендә нәтиҗәле коммуникацияләр системасын булдыру, шулай ук тикшеренүләр һәм эшләнмәләр секторының икътисадның реаль секторы белән, шул исәптән «Инноскоп» ачык инновацияләр Россия үзәге» интернет-порталы аша да, хезмәттәшлеген урнаштыру мәсьәләләре буенча бергәләп эшчәнлек алып бара.

4 статья

Авыл хуҗалыгы, дәүләт ветеринария күзәтчелеге һәм хайваннар дөньясының яшәеше тотрыклылыгы өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәге юнәлешләр буенча тәҗрибә алмаша:

үсемлекчелек, селекция, орлыкчылык, бөртекләләр һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын эшкәрткәндә, алдынгы технологияләрдән, үсемлекләр генофондыннан, үсемлекләрне саклауның экологик яктан чиста ысулларыннан һәм чараларыннан бергәләп файдалану;

терлекчелек, заманча технологияләргә нигезләнеп продукция бирүчәнлеге югары дәрәҗәдә булган авыл хуҗалыгы терлеген үрчетү, асрау һәм ашату; механикалаштырылган фермаларны техник яктан яңартуны тормышка ашыруга булышлык итү;

биотехнология, авыл хуҗалыгы культуралары җитештерүгә һәм терлекләр үрчетүгә биотехнологик идарә;

эшкәртү һәм азык-төлек сәнәгате, җитештерү процессында механикалаштыру һәм автоматлаштыру чараларын комплексны куллану.

5 статья

Яклар сәламәтлек саклау өлкәсендә фәнни-гамәли мәгълүмат алмашуга, Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсе территорияләрендә халык сәламәтлеген саклау өлкәсендә алдынгы тәҗрибәне өйрәнү һәм күрсәтелә торган медицина ярдәменең сыйфатын яхшырту максатында делегацияләр алмашуга булышлык итә.

6 статья

Яклар социаль яклау, халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

халыкны эш белән тәэмин итү, халыкка социаль ярдәм һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә, шул исәптән әлеге өлкәләрдә норматив хокукый документлар кабул итү һәм аларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча да, хезмәттәшлекне үстерә, социаль-икътисадый үсеш программаларын, гаиләгә, аналарга, балаларга, өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга ярдәм күрсәтү социаль программаларын гамәлгә ашыру буенча үзара хезмәттәшлекне һәм тәҗрибә уртаклашуны тормышка ашыра;

инновацияле технологияләр кертү өлкәсендә тәҗрибәне өйрәнү өчен халыкны социаль яклау һәм эш белән тәэмин итү органнары һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре делегацияләрен алмаша;

эшсезлек һәм хезмәт базарында хәлнең торышы буенча мәгълүмат-аналитика материаллары алмаша.

7 статья

Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү мәсьәләләре буенча халыкара хезмәттәшлек, Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсендә уздырылган чаралар турында мәгълүмат алмаша;

аеруча саклanучы табигать территорияләре өлкәсендә, кызыл китапларны алып бару, хайваннар дөньясы объектларын, су биоресурсларын саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә хезмәттәшлекне тәэмин итә;

түбәндәге мәсьәләләр буенча хезмәттәшлек итүгә һәм тәҗрибә алмашуга ярдәм итә: җитештерү һәм куллану калдыклары белән эшләү; калдыкларны сортларга аеру, эшкәртү һәм утильләштерүнең яңа технологияләрен кулланышка кертү; аерым саклanучы табигать территорияләренә идарә итү; табигатьне саклау структураларына идарәне камилләштерү.

8 статья

Мәдәният өлкәсендә Яклар үз компетенцияләре законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

аларда Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсе коллективлары һәм башкаручылары катнашу мөмкинлеген булдыру максатларында уздырылачак мәдәни вакыйгалар һәм чаралар, шул исәптән халыкара дәрәҗәдәге мәдәни вакыйгалар һәм чаралар турында мәгълүмат алмаша;

мәдәни бәйләнышларны ныгытуга һәм үстерүгә булышлык итә;

иҗат коллективлары гастрольләрен оештыру, музей, сынлы сәнгать һәм китап күргәзмәләрен алмашу буенча хезмәттәшлек итә;

мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы мәсьәләләре буенча да хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә алмаша.

9 статья

Архив эше өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

архив органнары һәм учреждениеләре эшчәнлегендә кулланылучы архив эше өлкәсендәге норматив һәм методик хезмәтләр, мәгълүмат технологияләре турында мәгълүмат һәм тәҗрибә алмаша;

фәнни-гамәли конференцияләр, семинарлар, киңәшмәләр, архив документлары күргәзмәләре оештыруда һәм уздыруда, Россия Федерациясе Архив фонды документлары буенча мәкаләләр әзерләүдә катнаша;

ике Якның да тикшеренүләр алып бару, законнар нигезендә гражданнарның социаль-хокукый яктан мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен кирәкле архив документларыннан һәм фәнни-белешмә материаллардан файдалану мөмкинлеген тикшерә.

10 статья

Мәгариф һәм фән өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

уртак конференцияләр уздыра;

уртак фәнни-тикшеренү проектларын тормышка ашыра;

заманча мәгариф технологияләре, мәгариф оешмалары эшчәнлеген җайга салучы норматив хокукый актлар проектларын эшләү буенча тәҗрибә алмаша;

этномәдәни белем бирүне саклау һәм үстерү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә уртаклаша.

11 статья

Мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

мәгълүмат технологияләре өлкәсендә, шул исәптән төрле инвестиция проектларын гамәлгә ашыру юлы аша үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерә;

яңа программалар белән тәэмин итү һәм аларны кулланышка кертү буенча тәҗрибә (шул исәптән техник алымнар) алмаша;

мәгълүмат технологияләре һәм элемтә тармакларын үстерү мәсьәләләре буенча алдынгы тәҗрибәне өйрәнү максатында Яклар вәкилләре делегацияләрен алмаша;

уртак предприятиеләр төзү яисә технологик хезмәттәшлек һәм укыту аша фәнни нигезгә корылган тармакларны үстерүгә этәргеч бирә.

## 12 статья

Спорт өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсе спортчылары һәм җыелма спорт командаларының спорт чараларында катнашуына булышлык итә.

Яклар спорт юнәлешендә Төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара физкультура чараларының һәм спорт чараларының бердәм календарь планы кысаларында аларга әзерлек максатларында спорт төрләре буенча ярышлар һәм күнекмә-тренировка җыеннары уздырганда хезмәттәшлек итә.

## 13 статья

Яклар яшьләр сәясәте өлкәсендә законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә Яклар тарафыннан уздырыла торган чараларда яшьләрнең катнашуына булышлык итә.

## 14 статья

Туристлык өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

Татарстан Республикасында һәм Чиләбе өлкәсендә уздырылачак туристлык чаралары турында мәгълүмат алмаша;

Татарстан Республикасының һәм Чиләбе өлкәсенең туристлык оешмалары арасында үзара элемтәләр урнаштыру мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә.

## 15 статья

Төзелеш, архитектура, энергетика һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

төзелешне оештыру, шәһәр төзелеше сәясәте, энергетика һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә тәҗрибә алмаша;

төзелеш, архитектура, энергетика һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсенә дәүләт хакимияте органнары делегацияләре алмаша;

төзелеш, архитектура, энергетика һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә кагылышлы халыкара, республика һәм өлкә күргәзмәләрендә, семинарларда һәм конференцияләрдә катнаша.

16 статья

Халыкара элемтәләр өлкәсендә Яклар Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсендә уздырыла торган халыкара чаралар турында бер-берсенә хәбәр итә.

17 статья

Бәяләрне (тарифларны) җайга салу өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә тарифларны җайга салу, хокук белемен куллану һәм контроль-күзәтчелек эшчәнлеге мәсьәләләре кысаларында тәҗрибә һәм мәгълүмат алмаша.

18 статья

Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә:

Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсе территорияләрендә яшәүче халыклар мәдәниятләренең якынаюына һәм үзара баюына булышлык итә;

Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсе территорияләрендә яшәүче халыкларның милли-мәдәни мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен кирәкле шартлар булдыра;

милли-мәдәни берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек буенча уртак проектлар эшләүдә һәм аларны тормышка ашыруда катнаша;

визитлар оештырганда делегацияләр составына милли-мәдәни берләшмәләр җитәкчеләрен кертү турында тәкъдимнәрне карап тикшерә.

19 статья

Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсенең массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең төбәк һәм төбәкара һөнәри белем бирү һәм мәгърифәти чараларда (форумнарда, фестивальләрдә, конференцияләрдә, семинарларда) бергәләп катнашуы мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә.

Яклар төбәк һәм муниципаль массакүләм мәгълүмат чараларына дәүләт ярдәме, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан тормышка ашырыла торган социаль әһәмияткә ия проектларга булышлык итү рәвешләре буенча тәҗрибә алмаша.

Яклар Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсе массакүләм мәгълүмат чаралары арасында Татарстан Республикасы һәм Чиләбе өлкәсенең иҗтимагый-сәяси, икътисадый, фәнни һәм мәдәни тормышына кагылышлы мәгълүмат алмашуны оештыра.

20 статья

Әлеге Килешү аңа кул куйган Якларга финанс һәм мөлкәт йөкләмәләре салмый.

21 статья

Әлеге Килешүне гамәлгә ашыру максатларында Яклар шартнамәләр (килешүләр), чаралар планнары төзергә, хезмәттәшлек итүнең конкрет өлкәләрендә уртак чаралар уздырырга хокуклы.

Әлеге Килешү Якларның һәр икесенең өченче як белән төзелгән килешүләрендә (шартнамәләрендә) билгеләнгән йөкләмәләренә кагылмый һәм Якларның кайсысының булса да мәнфәгатьләренә зыян китереп файдаланыла яисә Якларның теләсә кайсы өченче як алдында үз йөкләмәләрен үтәвенә киртә була алмый.

Әлеге Килешү нигезләмәләре аерым хуҗалык субъектларының эшчәнлеге өчен конкурентлыкны һәм башка хуҗалык субъектларының мәнфәгатьләрен чикләүгә китерүе мөмкин булган уңайлы шартлар тудыру дип карала алмый.

22 статья

Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру барышында килеп туган мәсьәләләрне тиз арада карап тикшерә һәм аларны уңай хәл итү өчен законнар нигезендә кирәкле чаралар күрә.

23 статья

Әлеге Килешүнең нигезләмәләрен шәрехләүдә һәм (яисә) кулланганда килеп чыгуы мөмкин булган фикер төрлелеге һәм бәхәсләрне Яклар сөйләшүләр һәм консультацияләр юлы белән хәл итә.

24 статья

Әлеге Килешү аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм биш ел дәвамында гамәлдә була. Алга таба Килешү, әгәр дә Якларның берсе үзенең әлеге Килешүне өзәргә теләве хакында язма рәвештә белдермәсә, аннан алдагы биш елга үзеннән-үзе озайтыла.

Әлеге Килешүнең гамәле Якларның берсе икенче Яктан Килешүнең гамәлен туктатырга нияте барлыгы турында язма хәбәр алганнан соң алты ай узгач, туктатыла.

Әлеге Килешүгә үзгәрешләр Якларның үзара ризалыгы белән әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган өстәмә килешүләр нигезендә кертелә.

2020 елның «1» октябрендә Чиләбе шәһәрендә рус һәм татар телләрендә һәркайсы бер үк төрле көчкә ия ике нөсхәдә, Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә башкарылды.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Хөкүмәте өчен | Чиләбе өлкәсе Хөкүмәте өчен |
| Татарстан Республикасы Президенты | Чиләбе өлкәсе Губернаторы |
| ____________ Р.Н. Миңнеханов | ____________ А.Л. Текслер |

02.10.2020
№ 22